КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 30 июль г.Казань № 619

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләрен раслау турында» 2017 ел, 29 декабрь, 1084 нче карары белән расланган 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләрен раслау турында» 2017 ел, 29 декабрь, 1084 нче карары белән расланган 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программаның VI бүлегендә:

12 бүлекчәнең 12.2 нче пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«махсуслаштырылган медицина ярдәме (югары технологияле медицина ярдәменнән тыш) күрсәтүне максимум көтү вакыты дәвалаучы табиб госпитализацияләүгә юллама биргән көннән – 30 календарь көннән дә артмаска тиеш, ә онкология авырулары белән пациентлар өчен шешне гистологик

верификацияләгән вакыттан яки авыру (хәл) диагнозын билгеләгән вакыттан алып 14 календарь көннән дә артмаска тиеш.»;

Программаның VII бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VII. Медицина ярдәме күрсәтү күләме нормативлары

Программа буенча, тулаем алганда, медицина ярдәме төрләре, шартлары һәм формалары буенча медицина ярдәме күрсәтү күләме нормативлары – 1 елга бер кешегә исәпләгәндә, Мәҗбүри медицина иминиятенең территориаль программасы буенча бер иминләштерелгән затка исәпләгәндә күләм берәмлекләрендә билгеләнә. Медицина ярдәме күләме нормативлары Программада каралган финанслар белән тәэмин итүнең җан башына исәпләнгән нормативлары күләмен планлаштыру һәм финанс-икътисадый нигезләү максатларында кулланыла һәм түбәндәге күләмнәрдә тәшкил итә:

медицина оешмасыннан читтә, медицина эвакуациясен дә кертеп, ашыгыч медицина ярдәме 2018 – 2020 елларга бер яшәүчегә – 0,02 чакыру, ММИ база программасы кысаларында бер иминләштерелгән затка – 0,3 чакыру;

амбулатория шартларында профилактика яки башка максатларда күрсәтелә торган медицина ярдәме (сәламәтлек үзәкләренә баруны, диспансеризация белән бәйле баруны, урта медицина персоналына баруны, шулай ук авырулар белән бәйле, шул исәптән авыз эче, төкерек бизләре һәм казналык авырулары (теш протезлаудан тыш) вакытында бер тапкыр баруларны кертеп) 2018 – 2020 елларга ММИ база программасы кысаларында бер иминләштерелгән затка – 2,35 бару, Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән – бер яшәүчегә 0,41 бару (паллиатив (шул исәптән өйдә) медицина ярдәме күрсәтү буенча баруны кертеп), шул исәптән:

медицина оешмалары өчен ММИ база программасы кысаларында:

медицина ярдәме күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – бер иминләштерелгән затка 2,07 бару;

медицина ярдәме күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – бер иминләштерелгән затка 0,28 бару;

медицина оешмалары өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән:

медицина ярдәме күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – бер яшәүчегә 0,4 бару;

медицина ярдәме күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – бер яшәүчегә 0,01 бару;

авырулар белән бәйле амбулатория шартларында 2018 – 2020 елларга ММИ база программасы кысаларында медицина ярдәме күрсәтү – бер иминләштерелгән затка 1,98 мөрәҗәгать (бер авыру белән кимендә ике тапкыр бару белән амбулатория шартларында авыруны дәвалауның тәмамланган очраклары), 2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән – бер яшәүчегә 0,08 мөрәҗәгать, шул исәптән:

медицина оешмалары өчен ММИ база программасы кысаларында:

медицина ярдәме күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – бер иминләштерелгән затка 1,87 мөрәҗәгать;

медицина ярдәме күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – бер иминләштерелгән затка 0,11 мөрәҗәгать;

медицина оешмалары өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән:

медицина ярдәме күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – бер иминләштерелгән затка 0,077 мөрәҗәгать;

медицина ярдәме күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – бер иминләштерелгән затка 0,003 мөрәҗәгать;

2018 – 2020 елларга ММИ база программасы кысаларында амбулатория шартларында ашыгыч формада күрсәтелә торган медицина ярдәме – бер иминләштерелгән затка 0,56 мөрәҗәгать, шул исәптән:

медицина оешмалары өчен ММИ база программасы кысаларында:

медицина ярдәме күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – бер иминләштерелгән затка 0,5 бару;

медицина ярдәме күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – бер иминләштерелгән затка 0,06 бару;

2018 – 2020 елларга ММИ база программасы кысаларында көндезге стационар шартларында күрсәтелә торган медицина ярдәме – бер иминләштерелгән затны дәвалауның 0,06 очрагы, 2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләре исәбеннән – бер яшәүчене дәвалауның 0,003 очрагы;

2018 – 2020 елларга ММИ база программасы кысаларында стационар шартларында күрсәтелә торган махсуслаштырылган медицина ярдәме – бер иминләштерелгән затка госпитализацияләүнең 0,17344 очрагы, шул исәптән 2018 елга ММИ база программасы кысаларында «Медицина тернәкләндерүе» юнәлеше буенча медицина ярдәме күрсәтүче махсуслаштырылган медицина оешмаларында һәм медицина оешмаларының тернәкләндерү бүлекләрендә медицина тернәкләндерүе – бер иминләштерелгән затка 0,03 койка-көн, 2019 елга – бер иминләштерелгән затка 0,058 койка-көн, 2020 елга – бер иминләштерелгән затка 0,07 койка-көн (шул исәптән чынбарлыктагы ихтыяҗны исәпкә алып, 0 – 17 яшьтәге балалар өчен медицина тернәкләндерүе өчен күләм нормативы: 2018 елга – бер иминләштерелгән затка 0,012 койко-көн, 2019 елга – бер иминләштерелгән затка 0,014 койко-көн, 2020 елга – бер иминләштерелгән затка 0,017 койко-көн), 2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән – бер затка госпитализацияләүнең 0,013 очрагы, шул исәптән:

медицина оешмалары өчен ММИ база программасы кысаларында:

медицина ярдәме күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – бер иминләштерелгән затка госпитализацияләүнең 0,04397 очрагы;

медицина ярдәме күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – бер иминләштерелгән затка госпитализацияләүнең 0,07932 очрагы;

медицина ярдәме күрсәтүнең өченче дәрәҗәсе – бер иминләштерелгән затка госпитализацияләүнең 0,05015 очрагы;

медицина оешмалары өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән:

медицина ярдәме күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – бер яшәүчегә госпитализацияләүнең 0,001 очрагы;

медицина ярдәме күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – бер яшәүчегә госпитализацияләүнең 0,005 очрагы;

медицина ярдәме күрсәтүнең өченче дәрәҗәсе – бер яшәүчегә госпитализацияләүнең 0,007 очрагы;

2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стационар шартларда паллиатив медицина ярдәме (хосписларны һәм шәфкать туташы каравы гамәлгә ашырыла торган хастаханәләрне кертеп) – бер яшәүчегә 0,018 койка-көн.

Программа буенча, тулаем алганда, югары технологияле медицина ярдәме (шул исәптән федераль башкарма хакимият органнарының ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары тарафыннан күрсәтелә торган ММИ база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү) күләме 2018 – 2020 елларга бер яшәүчегә исәпләгәндә госпитализацияләүнең 0,0058 очрагы.»;

Программаның VIII бүлегендә:

1 пунктның икенче – тугызынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән ашыгыч медицина ярдәмен бер тапкыр чакыру – 2 598,7 сум, ММИ акчасы исәбеннән – 2 224,6 сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән медицина оешмаларының (аларның структур бүлекчәләренең) амбулатория шартларында медицина ярдәме күрсәткәндә профилактика һәм бүтән максатларда бер бару (паллиатив (шул исәптән өйдә) медицина ярдәме күрсәтү буенча баруны кертеп) – 522,5 сум, ММИ акчасы исәбеннән – 468,6 сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән медицина оешмаларының (аларның структур бүлекчәләренең) амбулатория шартларында медицина ярдәме күрсәткәндә, авыруга бәйле рәвештә, бер мөрәҗәгать итү – 1 603,4 сум, ММИ акчасы исәбеннән – 1 267,7 сум;

ММИ акчасы исәбеннән амбулатория шартларында ашыгыч формада медицина ярдәме күрсәткәндә бер бару – 579,3 сум;

көндезге стационар шартларында дәвалауның бер очрагы: Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 15 427,5 сум, ММИ акчасы исәбеннән – 14 619,5 сум;

стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында (аларның структур бүлекчәләрендә) госпитализацияләүнең бер очрагы: Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 100 038,5 сум, ММИ акчасы исәбеннән – 29 910,7 сум;

«Медицина тернәкләндерүе» юнәлеше буенча медицина ярдәме күрсәтүче махсуслаштырылган медицина оешмаларында һәм медицина оешмаларының тернәкләндерү бүлекләрендә медицина тернәкләндерүе буенча бер койка-көн ММИ акчасы исәбеннән – 2 106,0 сум;

стационар шартларда паллиатив медицина ярдәме (хосписларны һәм шәфкать туташы каравы гамәлгә ашырыла торган хастаханәләрне кертеп)

күрсәтүче медицина оешмаларында (аларның структур бүлекчәләрендә) бер койка-көн Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 2 561,1 сум.»;

11 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Программада каралган финанслауның җан башына исәпләнгән нормативлары (федераль бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча) түбәндәгечә тәшкил итә:

Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләре исәбеннән (бер яшәүчегә исәпләгәндә) 2018 елда – 3 442,7 сум, 2019 елда – 3 380,4 сум, 2020 елда – 3 500,2 сум;

ММИ база программасын финанслауга ММИ акчасы исәбеннән (бер иминләштерелгән затка исәпләгәндә) 2018 елда – 10 772,6 сум, 2019 елда – 11 154,1 сум, 2020 елда – 11 600,8 сум.

2018 елда Программаның кыйммәте – 54 093 471,1 мең сум, 2019 елда – 55 293 494,2 мең сум, 2020 елда – 57 447 389,9 мең сум (бу Программага теркәлгән 3 нче һәм 4 нче кушымталар), шул исәптән:

2018 елда база программасын тормышка ашыруга ММИ акчасы исәбеннән – 40 717 602,9 мең сум, 2019 елда – 42 159 645,7 мең сум, 2020 елда – 43 848 102,5 мең сум;

2018 елда Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләре исәбеннән – 13 375 868,2 мең сум, 2019 елда – 13 133 848,5 мең сум, 2020 елда – 13 599 287,4 мең сум.»;

Программага теркәлгән 1 нче кушымтада:

54 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «54. | «АлСтом» стоматология поликлиникасы» акционерлар җәмгыяте | + | | | +»; |

181 нче пунктны төшереп калдырырга;

1 графада 181 нче номердан башлап пунктларның алга таба нумерациясен үзгәртергә;

түбәндәге эчтәлекле 221 нче, 222 нче пунктлар өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «221. | Җаваплылыгы чикләнгән «ФармГрупп» җәмгыяте | + | | | | |
| 222. | Җаваплылыгы чикләнгән «ИННОВАЦИОН МЕДИЦИНА КЛИНИКАСЫ» җәмгыяте | + | | | | »; |

Программага теркәлгән 3 нче һәм 4 нче кушымталарны (карарга теркәләләр) яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Бу карарның көче 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына
3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
2018 ел, 30 июль, 619 нчы
карары редакциясендә)

## 2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына финанслар белән тәэмин итү чыганаклары буенча гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре территориаль программасы кыйммәте

| Гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасын финанслар белән тәэмин итү чыганаклары | Юл саны | 2018 ел | | План чоры | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 ел | | 2020 ел | |
| | | территориаль программаның расланган кыйммәте | | территориаль программаның кыйммәте | | территориаль программаның кыйммәте | |
| | | барлыгы, мең сум | бер кешегә (Мәҗбүри медицина иминияте буенча бер иминләштерелгән затка) 1 елга (сум) | барлыгы, мең сум | бер кешегә (Мәҗбүри медицина иминияте буенча бер иминләштерелгән затка) 1 елга (сум) | барлыгы, мең сум | бер кешегә (Мәҗбүри медицина иминияте буенча бер иминләштерелгән затка) 1 елга (сум) |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| Дәүләт гарантияләренең территориаль программасы кыйммәте – барлыгы (02 +03 юллар суммасы) шул исәптән: | 01 | 54 093 471,1 | 14 215,3 | 55 293 494,2 | 14 534,5 | 57 447 389,9 | 15 01,0 |
| I.Россия Федерациясе субъектының берләштерелгән бюджеты акчасы* | 02 | 13 375 868,2 | 3 442,7 | 13 133 848,5 | 3 380,4 | 13 599 287,4 | 3 500,2 |
| II.Мәҗбүри медицина иминиятенең территориаль программасы кыйммәте – барлыгы (04 + 08 юллар суммасы) | 03 | 40 717 602,9 | 10 772,6 | 42 159 645,7 | 11 154,1 | 43 848 102,5 | 11 600,8 |
| 1. База программа кысаларында мәҗбүри медицина иминияте акчасы исәбеннән мәҗбүри медицина иминиятенең территориаль программасы кыйммәте** | 04 | 40 717 602,9 | 10 772,6 | 42 159 645,7 | 11 154,1 | 43 848 102,5 | 11 600,8 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| (05+ 06 + 07 юллар суммасы) | | | | | | | |
| 1.1. Мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан субвенцияләр** | 05 | 40 666 529,0 | 10 759,1 | 42 159 645,7 | 11 154,1 | 43 848 102,5 | 11 600,8 |
| 1.2. Мәҗбүри медицина иминиятенең база программасы өлешендә мәҗбүри медицина иминиятенең территориаль программасын финанслар белән тәэмин итүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының бюджетара трансфертлары | 06 | | | | | | |
| 1.3. Башка керемнәр | 07 | 51 073,9 | 13,5 | | | | |
| 2. Мәҗбүри медицина иминиятенең база программасы белән билгеләнмәгән медицина ярдәмен күрсәтүнең өстәмә төрләрен һәм шартларын финанслар белән тәэмин итүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының бюджетара трансфертлары, шул исәптән: | 08 | | | | | | |
| 2.1. Медицина ярдәменең өстәмә төрләрен финанслар белән тәэмин итү өчен территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 09 | | | | | | |
| 2.2. Мәҗбүри медицина иминиятенең база программасы кысаларындагы медицина ярдәме өчен түләүгә тарифлар структурасына кертелмәгән чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 10 | | | | | | |

* Гражданнарның аерым категорияләренә дару препаратлары белән тәэмин итү буенча дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә федераль бюджеттан бюджет ассигнованиеләрен исәпкә алмыйча, максатчан программалар, шулай ук бюджетара трансфертлар (06 һәм 10 юллар);

** Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларының территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турындагы законда 01 «Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлеге буенча күздә тотылган үз функцияләрен үтәвен тәэмин итүгә чыгымнарны исәпкә алмыйча.

| Белешмә өчен | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | барлыгы, мең сум | бер иминләштерелгән затка, сум | барлыгы, мең сум | бер иминләштерелгән затка, сум | барлыгы, мең сум | бер иминләштерелгән затка, сум |
| Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларының үз функцияләрен үтәвен тәэмин итүгә чыгымнар | 202 773,80 | 53,6 | 208 706,00 | 55,2 | 215 089,10 | 56,9 |

2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына
4 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 30 июль, 619 нчы карары редакциясендә)

## 2018 елга медицина ярдәме күрсәтү шартлары буенча гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре территориаль программасының расланган кыйммәте

| Финанслар белән тәэмин итү чыганаклары һәм аларны күрсәтү шартлары буенча медицина ярдәме | Юл саны | Үлчәү берәмлеге | 1 кешегә исәпләгәндә медицина ярдәме күләме (1 иминиятләштерелгән затка исәпләгәндә медицина ярдәме күрсәтү күләмнәре нормативы) | Медицина ярдәме күләменең берәмлеге кыйммәте (медицина ярдәме күрсәтү күләме берәмлегенә финанс чыгымнар нормативы) | Территориаль программаны финанслауның җан башына исәпләнгән нормативлары, сум | | | Территориаль программаның финанслар белән тәэмин ителү чыганаклары буенча кыйммәте, мең сум | | | йомгакка карата % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Россия Федерациясе субъектының берләштерелгән бюджеты акчасы исәбеннән | | Мәҗбүри медицина иминияте акчасы исәбеннән | Россия Федерациясе субъектының берләштерелгән бюджеты акчасы исәбеннән | | Мәҗбүри медицина иминияте акчасы исәбеннән | |
| | | | | | бюджет акчасы | Мәҗбүри медицина иминияте системасы аша бюджетның нигездә бер каналлы финанслауны тормышка ашыруга Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бирелә торган акчасы | | бюджет акчасы | Мәҗбүри медицина иминияте системасы аша бюджетның нигездә бер каналлы финанслауны тормышка ашыруга Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бирелә торган акчасы | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6.1 | 6.2 | 7 | 8.1 | 8.2 | 9 | 10 |
| I. **Россия Федерациясе субъектының** | **01** | | х | х | 1 504,2 | 1 938,5 | х | 5 844 441,9 | 7 531 426,3 | х | 24,7 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6.1 | 6.2 | 7 | 8.1 | 8.2 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **берләштерелгән бюджеты акчасы исәбеннән күрсәтелә торган медицина ярдәме, шул исәптән** *: | | | | | | | | | | | |
| 1. Ашыгыч, шул исәптән ММИ территориаль программасына кертелмәгән ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме | 02 | чакырулар | 0,02 | 2 598,7 | 0,0 | 55,0 | х | 0,0 | 213 503,1 | х | х |
| шул исәптән ММИ системасында идентификацияләнмәгән һәм иминләштерелмәгән затларга | 03 | чакырулар | 0,01 | 2 249,7 | 0,0 | 33,3 | х | 0,0 | 129 461,4 | х | х |
| 2. Амбулатория шартларында медицина ярдәме | 04 | профилактика максатында һәм башка максатларда барулар | 0,41 | 522,5 | 0,0 | 214,2 | х | 0,0 | 832 203,8 | х | х |
| | 05 | мөрәҗәгатьләр | 0,08 | 1 603,4 | 0,0 | 131,4 | х | 0,0 | 510 539,3 | х | х |
| шул исәптән ММИ системасында идентификацияләнмәгән һәм иминләштерелмәгән затларга | 06 | профилактика максатында һәм башка максатларда барулар | 0,00 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | х | 0,0 | 0,0 | х | х |
| | 07 | мөрәҗәгатьләр | 0,005 | 558,8 | 0,0 | 2,7 | х | 0,0 | 10 320,8 | х | х |
| 3. Стационар шартларында махсуслаштырылган медицина ярдәме | 08 | госпитальләштерү очраклары | 0,010 | 77 205,4 | 137,1 | 631,1 | х | 532 651,2 | 2 452 110,2 | х | х |
| шул исәптән ММИ системасында идентификацияләнмәгән һәм иминләштерелмәгән затларга | 09 | госпитальләштерү очраклары | 0,001 | 12 838,1 | 0,0 | 15,7 | х | 0,0 | 61 135,0 | х | х |
| 4. Көндезге стационар шартларында медицина ярдәме | 10 | дәвалану очраклары | 0,003 | 15 427,5 | 0,0 | 48,1 | х | 0,0 | 186 950,7 | х | х |
| шул исәптән ММИ системасында идентификацияләнмәгән һәм иминләштерелмәгән затларга | 11 | дәвалану очраклары | 0,0000 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | х | 0,0 | 0,0 | х | х |
| 5. Паллиатив медицина ярдәме | 12 | койка-көннәр | 0,018 | 2 561,1 | 1,4 | 43,4 | х | 5 605,3 | 168 712,9 | х | х |
| 6. Башка дәүләт хезмәтләре күрсәтү (эшләр башкару) | 13 | - | х | х | 1 365,7 | 259,3 | х | 5 306 185,4 | 1 007 387,2 | х | х |
| 7. Россия Федерациясе субъектының медицина оешмаларында күрсәтелә торган югары технологияле медицина ярдәме | 14 | госпитальләштерү очраклары | 0,003 | 169 174,4 | 0,0 | 556,0 | х | 0,0 | 2 160 019,1 | х | х |
| II. Мәҗбүри медицина иминияте системасында эшли торган медицина оешмалары өчен медицина җиһазын сатып алуга Россия Федерациясе субъектының берләштерелгән бюджеты акчасы**, шул исәптән сатып алуга: | **15** | | х | х | 0,0 | 0,0 | х | 0,0 | 0,0 | х | 0,0 |
| санитар транспорт | 16 | _ | х | х | 0,0 | 0,0 | х | 0,0 | 0,0 | х | х |
| компьютер томографиясе | 17 | - | х | х | 0,0 | 0,0 | х | 0,0 | 0,0 | х | х |
| магнитлы-резонанслы томография | 18 | . | х | х | 0,0 | 0,0 | х | 0,0 | 0,0 | х | х |
| башка медицина җиһазы | 19 | - | х | х | 0,0 | 0,0 | х | 0,0 | 0,0 | х | х |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6.1 | 6.2 | 7 | 8.1 | 8.2 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| III. Мәҗбүри медицина иминиятенең территориаль программасы кысаларында медицина ярдәме: | **20** | | х | х | х | х | 10 772,6 | х | 0,0 | 40 717 602,9 | 75,3 |
| ашыгыч медицина ярдәме (29+34 юллар суммасы) | 21 | чакырулар | 0,30 | 2 224,6 | х | 0,0 | 667,4 | х | 0,0 | 2 522 529,6 | х |
| амбулатория шартларында медицина ярдәме | 22.1 | профилактика максатында һәм башка максатларда барулар | 2,35 | 468,6 | х | 0,0 | 1 102,5 | х | 0,0 | 4 167 177,8 | х |
| | 22.2 | кичектергесез медицина ярдәме күрсәтү буенча барулар | 0,56 | 579,3 | х | 0,0 | 325,4 | х | 0,0 | 1 230 013,4 | х |
| | 22.3 | мөрәҗәгатьләр | 1,98 | 1 267,7 | х | 0,0 | 2 515,1 | х | 0,0 | 9 506 559,8 | х |
| стационар шартларда (31 + 33 юллар суммасы) махсуслаштырылган медицина ярдәме, шул исәптән: | 23 | госпитальләштерү очраклары | 0,17344 | 29 910,7 | х | 0,0 | 5 187,8 | х | 0,0 | 19 608 696,6 | х |
| стационар шартларда медицина тернәкләндерүе (31.1+36.1 юллар суммасы) | 23.1 | койка-көннәр | 0,030 | 2 106,0 | х | 0,0 | 62,9 | х | 0,0 | 237 775,0 | х |
| югары технологияле медицина ярдәме (31.2+36.2 юллар суммасы) | 23.2 | госпитальләштерү очраклары | 0,0020 | 169 771,3 | х | 0,0 | 336,6 | х | 0,0 | 1 272 266,0 | х |
| көндезге стационар шартларда медицина ярдәме (32 + 37 юллар суммасы)) | 24 | дәвалану очраклары | 0,06 | 14 619,5 | х | 0,0 | 878,7 | х | 0,0 | 3 320 917,1 | х |
| паллиатив медицина ярдәме *** (38 юлга тигез) | 25 | койка-көннәр | | | | | | | | 0,0 | х |
| массакүләм хезмәт күрсәтү системасы эшен алып баруга чыгымнар | 26 | - | х | х | х | х | 95,7 | х | | 361 708,6 | х |
| башка чыгымнар (39 юлга тигез) | 27 | | | | | | 0,0 | | | 0,0 | |
| 20 юлдан:<br>1. Мәҗбүри медицина иминияте база программасы кысаларында иминиятләштерелгән затларга күрсәтелә торган медицина ярдәме | 28 | | | х | х | х | 10 676,9 | х | х | 40 355 894,3 | 74,6 |
| ашыгыч медицина ярдәме | 29 | чакырулар | 0,30 | 2 224,6 | х | х | 667,4 | х | х | 2 522 529,6 | х |
| амбулатория шартларында медицина ярдәме | 30.1 | профилактика максатында һәм башка максатларда барулар | 2,35 | 468,6 | х | х | 1 102,5 | х | х | 4 167 177,8 | х |
| | 30.2 | кичектергесез медицина ярдәме күрсәтү буенча барулар | 0,56 | 579,3 | х | х | 325,4 | х | х | 1 230 013,4 | х |
| | 30.3 | мөрәҗәгатьләр | 1,98 | 1 267,7 | х | х | 2 515,1 | х | х | 9 506 559,8 | х |
| стационар шартларда махсуслаштырылган медицина ярдәме, шул исәптән | 31 | госпитальләштерү очраклары | 0,17344 | 29 910,7 | х | х | 5 187,8 | х | х | 19 608 696,6 | х |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6.1 | 6.2 | 7 | 8.1 | 8.2 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| стационар шартларда медицина тернәкләндерүе | 31.1 | койка-көннәр | 0,030 | 2 106,0 | x | x | 62,9 | x | x | 237 775,0 | x |
| югары медицина ярдәме | 31.2 | госпитальләштерү очраклары | 0,002 | 169 771,3 | x | x | 336,6 | x | x | 1 272 266,0 | x |
| көндезге стационар шартларда медицина ярдәме | 32 | дәвалану очраклары | 0,06 | 14 619,5 | x | x | 878,7 | x | x | 3 320 917,1 | x |
| 2. База программасыннан тыш төрләр һәм авырулар буенча медицина ярдәме: | 33 | | x | x | x | x | x | x | x | 0,0 | 0,0 |
| ашыгыч медицина ярдәме | 34 | чакырулар | | | | | | | | | |
| амбулатория шартларында медицина ярдәме | 35.1 | профилактика максатында һәм башка максатларда барулар | | | | | | | | | |
| | 35.2 | кичектергесез медицина ярдәме күрсәтү буенча барулар | | | | | | | | | |
| | 35.3 | мөрәҗәгатьләр | | | | | | | | | |
| стационар шартларда махсуслаштырылган медицина ярдәме, шул исәптән | 36 | госпитальләштерү очраклары | | | | | | | | | |
| стационар шартларда медицина тернәкләндерүе | 36.1 | койка-көннәр | | | | | | | | | |
| югары технологияле медицина ярдәме | 36.2 | госпитальләштерү очраклары | | | | | | | | | |
| көндезге стационар шартларда медицина ярдәме | 37 | дәвалану очраклары | | | | | | | | | |
| паллиатив медицина ярдәме | 38 | койка-көннәр | | | | | | | | | |
| башка чыгымнар | 39 | | | | | | | | | | |
| **Барлыгы (01 + 15 + 20 юллар суммасы)** | **40** | | x | x | 1 504,2 | 1 938,5 | 10 772,6 | 5 844 441,9 | 7 531 426,3 | 40 717 602,9 | 100,0 |

* Мәҗбүри медицина иминияте системасында эшләүче медицина оешмалары өчен җиһаз сатып алу өчен Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының финанс чараларын исәпкә алмыйча (тарифка кермәгән чыгымнар).

** Мәҗбүри медицина иминияте системасында эшләүче медицина оешмалары өчен медицина җиһазы сатып алу өчен, мәҗбүри медицина иминиятенең территориаль программасыннан тыш, Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджеты чыгымнары күрсәтелә.

*** Территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасына паллиатив медицина ярдәме Татарстан Республикасының тиешле түләүләре белән мәҗбүри медицина иминиятенең база программасыннан тыш кертелгән очракта.

2017 елның 1 апреле хәленә карата Татарстан Республикасында Мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән затлар саны – 3 779 750 кеше;

Дәүләт статистикасы федераль хезмәте мәгълүматлары буенча, 2017 елның 1 гыйнвары хәленә карата Татарстан Республикасында даими яшәүче гражданнар саны – 3 885 253 кеше.

___